ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.04.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 952**

«Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында

«Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренә түләүне камилләштерү максатларында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында нигезләмәне расларга.
2. «Айныткыч»муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү өчен «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында» гы 2018 елның 24 апрелендәге ЗМР БК 976 номерлы карарының гамәли көчен җәелдермәскә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 апрелендәге 842 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.ru)урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 3 апрелендәге
952 номерлы карарына
1 нче кушымта

"«Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында нигезләмә

1. «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтен оештыру һәм аларның хезмәт шартлары турында әлеге нигезләмә(алга таба-Нигезләмә) эшчәнлекне оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең эш хакы айлык вазыйфаи окладыннан, тиешле елларны эшләгән өчен айлык вазыйфаи окладына өстәмә түләүдән, катлаулы һәм киеренкелек өчен айлык вазыйфаи окладына өстәмә түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора. Белгечләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштергән өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәү һәм хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча айлык компенсация түләүләре кертелә.

3. «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Башлык | 25800 |
| Башлык урынбасары | 23200 |
| Баш белгеч | 14000 |
| Әйдәп баручы белгеч | 12700 |

4. «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренә түбәндәгеләр билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен түбәндәге күләмнәрдә өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмәләр, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

Предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең аерым вазыйфаларындагы хезмәт эшчәнлеге чоры, вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле тәҗрибә һәм белем түбәндәге стажга кертелергә мөмкин:

а) дәүләт (муниципаль) учреждениеләрендә (казна, бюджет, автоном) эшләү вакыты, муниципаль казна учреждениесендә, аларның белгечлеге муниципаль казна учреждениесендә биләгән белгечлеккә туры килә торган, хезмәткәрләр вазифалары буенча эшнең башка чорлары кертелә;

б) дәүләт хезмәтенең дәүләт вазыйфалары реестрында каралган дәүләт хезмәтенең дәүләт вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләре, кимендә өч ел;

в) федераль законда билгеләнгән тәртиптә хәрби хезмәт чорлары, эчке эшләр органнарында, салым полициясендә, таможня органнарында һәм җинаять-үтәтү системасы органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә хезмәт чорлары кертелә;

г) Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында сайланулы муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфаларын биләү чорлары кертелә.

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге (эшчәнлек үзенчәлеге) өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

4) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм.

5. Түбәндәге өстәмә түләүләр билгеләргә:

1) һөнәрләрне бергә алып барган, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм эш урынында вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазифаларын үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча башкарган өчен, билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә, төп эш буенча вазифаи окладының 50 процентына кадәр күләмендә өстәмә түләүләр.

2) төнлә эшләгән өчен белгечләргә (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) вазыйфаи окладның һәр сәгатькә төнлә эшләү өчен исәпләнгән сәгатьлек тариф ставкасының 20 проценты күләмендә;

3) бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен - икеләтә көнлек тариф ставкасы күләмендә;

4) хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча белгечләргә вазифаи окладының 10 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

6. Хезмәткәрләргә бирелгән субвенцияләр кысаларында, тиешле федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләрне бирергә.

7. Учреждение җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның (компенсация түләүләрен исәпкә алып) суммасыннан тыш, түләүгә (бер елга исәпләгәндә) түбәндәге акчалар каралган:

тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә - 1,8 вазыйфаи оклад;

җитәкчеләр һәм белгечләрнең махсус эш режимы, эшенең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык вазифаи окладка өстәмә түләү-1,2 вазыйфаи оклад күләмендә;

төнлә эшләгән өчен белгечләргә вазыйфаи окладның һәр сәгатькә төнлә эшләү өчен исәпләнгән сәгатьлек тариф ставкасының 20 проценты күләмендә;

хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча белгечләргә айлык өстәмә түләү- 1,2 вазыйфаи оклад күләмендә;

8. «Айныткыч» муниципаль казна махсус учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә дип билгеләргә;

оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладларын арттыру, җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бирелгән субвенцияләр кысаларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча гамәлгә ашырыла;

әлеге карар кабул ителгәнлектән, учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең башка шартлары кулланылмый.